КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 июнь г.Казань № 599

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының аерым дәүләт учреждениеләре норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 30 сентябрь, 932 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының аерым дәүләт учреждениеләре норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 30 сентябрь, 932 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 гыйнвар, 70 нче; 2022 ел, 11 февраль, 118 нче; 2022 ел, 8 апрель, 329 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының аерым дәүләт учреждениеләре башкара торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарда:

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2.5. | «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | музей әйберләрен, музей коллекцияләрен булдыру, исәпкә алу, өйрәнү, аларның физик сакланышын һәм иминлеген тәэмин итү | 2 775 122,77 |
| | | музей әйберләрен, музей коллекцияләрен реставрацияләүне һәм консервацияләүне гамәлгә ашыру | 8 880 392,85 |
| | | музейлар экспозицияләрен (күргәзмәләрен) төзү, күргәзмәләр оештыру | 2 220 098,21»; |

2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2.10. | «Ленино-Кокушкино» дәүләт тарихи-мәдәни музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | музей әйберләрен, музей коллекцияләрен булдыру, исәпкә алу, өйрәнү, аларның физик сакланышын һәм иминлеген тәэмин итү | 689 055,43 |
| | | музейлар экспозицияләрен (күргәзмәләрен) төзү, күргәзмәләр оештыру | 519 813,74»; |

3.3 пунктының 4 графасында «20 893 600,0» саннарын «23 458 600,0» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының аерым дәүләт учреждениеләре башкара торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарда һәм аларның күләмнәрендә:

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «2.5. | «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | музей әйберләрен, музей коллекцияләрен халыкка күрсәтү | 5 015,33 | 24 900,0 | музей экспонатлары саны, берәмлек»; |

2.10 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин